СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                        КАРАР

26.10.2021                с. Верхний Услон                № 10-112

Югары Ослан муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару
Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020нче елның 8нче июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Налог һөнәри керемгә» (үз-үзләрен мәшгуль гражданнар) махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм чараларын күрсәтү максатларында,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының 2016нчы елның 27нче октябрендәге 15-159нчы номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару» Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең исеме түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары Ослан муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат хокукларыннан ирекле булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), шулай «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы индивидуаль

эшкуарлар булмаган һәм физик затларга муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе»;

1.2. - Тәртипнең 1.3 Пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) файдалануга кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шулай ук «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын (җир кишәрлекләреннән тыш) кулланучы индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм физик затларга, түләүле озак сроклы нигездә, шул исәптән ташламалы шартларда, муниципаль милек исемлеген (алга таба - Исемлек) формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару процедурасын билгели»;

1.3. - Тәртипнең 1.3 Пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәт, мондый мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле читләштерүдән тыш, "Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалаган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008нче елның 22нче июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39_3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда хосусый милеккә күчерелергә тиеш түгел».

2. «Югары Ослан муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат хокукларыннан ирекле булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), шулай «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм физик затларга муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен яңа редакциядә расларга (1нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының икътисади үсеш, экология, табигый ресурслар һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зыятдинов